Кvп сойлибез, кvп язабыз, барыбер алданабыз. Мәгълvмат-телекоммуникация технологияләре олкәсендә дистанцион жинаятьләрне профилактикалау һәм кисәтv турында гражданнар очен белешмәлек тәгъдим итәбез. Аны Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы әзерләгән.      Мошенникларнын корбаны булмас очен тvбәндәгеләрне белергә кирәк: теләсә кайсы банк хезмәткәрләре сезнен картанын мәгълvматларын (картанын номеры, анын гамәлдә булу вакыты, картанын арткы ягындагы яшерен код) хәбәр итvне беркайчан да сорамыйлар, чонки аларда һичшиксез сезнен мәгълvматлар бар.; сезнен банк картасы мәгълvматларын, шулай ук картанын арткы ягындагы яшерен кодны нинди шартларда хәбәр итмәскә.
Пин-кодны картадан аерым сакларга, һич кенә дә пин-кодны банк картасынын vзендә язмаска һәм пин-кодны очение затларга хәбәр итмәскә.
Сезне ялгыш юлга этәрергә тырышкан «телефон» мошенникларыннан сакланырга.
Үзләрен банк хезмәткәрләре дип таныштыручы шикле кешеләр белән телефоннан сойләшvдән саклану яхшырак, әнгәмәне озvдән курыкмагыз, трубканы куегыз гына.
Банктан килгән СМС хәбәрләрен игътибар белән укыгыз; беркайчан да, беркемгә дә парольләр һәм Банктан СМС-хәбәрдә килгән яшерен кодларны хәбәр итмәгез.
Исегездә тотыгыз: бары тик мошенниклар гына Банктан СМС хәбәрендә килгән яшерен парольләрне сорый, банк хезмәткәрләре беркайчан да сездән банкомат янына узуыгызны сорамаячак. Әгәр сездән банк картасы белән банкоматка барырга сорасалар, бу мошенниклар булса кирәк.
Интернет-кибетләр турында. Товарны ачыктан-ачык киметелгән бәядән сатып алмагыз, чонки бу мошенниклар эше.
Әгәр социаль челтәрдәге танышыгыз сездән моны эшләргә сораса, бәлки, мошенниклар аккаунтны ватканнардыр, башта бу кеше белән элемтәгә керегез һәм ул сездән чыннан да акча сорыймы икәнен белегез.
«Интернет» челтәрендә билгесез сайтларга сылтамалар буенча кvчмәгез: уйлап эш итегез, ашыкмагыз, «бушлай сыр тычкан тозагында гына» икәнен исегездә тотыгыз.
Мошенникларга бары тик игътибарлылык, аек акыл һәм уяулык белән генә каршы торырга момкин.